# <u>**Судка иск бирү тәртибе**</u>

Кулланучыларның хокукларын суд яклый. Шунысын да исәпкә алырга кирәк, кулланучы – товарга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бары тик шәхси яки эшкуарлык эшчәнлеге белән бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен заказ бирүче, сатып алучы, файдаланучы гражданин.

<u>*Кулланучы сайлавы буенча иск бирелергә мөмкин:*</u>

- <u>*җаваплы затның (сатучы, товарны ясаучы, эшләрне башкаручы) урнашкан урыны буенча*</u>. Оешмаларга иск оешма урнашкан урын буенча бирелә, җаваплы зат шәхси эшкуар булса – аның яшәү урыны буенча бирелә;
- *кулланучының яшәү яки тору урыны буенча;*
- *килешү төзелү яки башкарылу (товар сатылу яки хезмәт күрсәтелү) урыны буенча*;
- *төп оешманың (сатучының, товарны ясаучының, хезмәт күрсәтүченең) филиалы яки вәкиллеге урнашу урыны буенча.*

Иск бәясе 50 мең сумга кадәр булганда иск *җәмәгать судьясына,* аннан артыграк булганда – *район судына* юллана.

Әгәр дә иск бәясе 1 000 000 сумнан артык булмаса, кулланучылар хокукларын яклау турындагы иск белән мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт пошлинасын түләмиләр.

Әгәр дә иск бәясе 1 000 000 сумнан арык булса, дәүләт пошлинасы РФ СК 333.19 статьясының 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә исәпләнгән һәм иск 1 000 000 сумлык булганда түләнергә тиешле дәүләт пошлинасы суммасына кечерәйтелгән суммада түләнә.

*Сатучыга (башкаручыга) судка кадәр мәҗбүри рәвештә ризасызлык белдерү <u>каралмаган.</u>*

Әмма, практика күрсәткәнчә, претензияне искка кадәр юллау бәхәсләрне тизрәк (озакка сузылган суд процедураларыннан башка) хәл итү яки алга таба иск таләпләре буенча раслау процессын җиңеләйтү мөмкинлеген бирә.